| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

26.10.2023 Баулы шәһәре № 222

Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 16 октябрендәге 222 номерлы “Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында” карарына өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына ярашлы рәвештә Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 16 октябрендәге 222 номерлы “Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында” (Баулы муниципаль районы Советының 2020 елның 29 маендагы 262 номерлы, 2022 елның 11 апрелендәге 110 номерлы, 202 елның 14 августындагы 126 номерлы, 2023 елның 2 февралендәге 162 номерлы, 2023 елның 20 июнендәге 191 номерлы карарлары белән керткән үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

33.1 статья белән түбәндәге эчтәлектә өстәмә кертергә:

«33.1. Статья Озак вакытлы бюджет планлаштыру

1. Озак вакытлы бюджет планлаштыру, Баулы муниципаль районының озак вакытлы чорга бюджет фаразын формалаштыру юлы белән башкарыла.

2. Баулы муниципаль районының озак вакытлы чорга бюджет фаразы дип, Баулы муниципаль районының консолидацияләнгән бюджетының төп характеристикаларын фаразлаучы документ аңлатыла, Баулы муниципаль районының муниципаль программаларын гамәлдә булган чорда финанс тәэмин итү күрсәткечләре, Баулы муниципаль районының берләштерелгән бюджетын билгеләүче башка күрсәткечләр, шулай ук озак вакытлы чорга Баулы муниципаль районының бюджет сәясәтен

формалаштыруга төп карашларны үз эченә ала.

3. Баулы муниципаль районының озак вакытлы чорга бюджет фаразы һәр өч ел саен алты елга, Баулы муниципаль районының тиешле чорга социаль - икътисади үсеше нигезендә эшләнә.

Баулы муниципаль районының озак вакытлы чорга бюджет фаразы, тиешле чорга Баулы муниципаль районының социаль - икътисади үсеше фаразының үзгәрүен һәм Баулы муниципаль районы Советының Баулы муниципаль районы бюджеты турында аның гамәлдә булу чорын озайтмыйча кабул ителгән карарын исәпкә алып үзгәртелергә мөмкин.

4. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Карарның таләпләрен үтәп, Баулы муниципаль районының озак вакытлы чорга бюджет фаразының эшләү һәм раслау тәртибе, эшләү чоры, шулай ук составына һәм эчтәлегенә таләпләр, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

5. Баулы муниципаль районының озак вакытлы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразының үзгәрүе), Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Баулы муниципаль районы бюджеты турында Баулы муниципаль районы Советы карары рәсми рәвештә бастырылып чыкканнан соң ике айдан да артмаган вакыт эчендә раслана.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
Район Советы Рәисе И.И. Гузаиров